СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**№ 35**

**22.09.2017 ел**

## Референдум уздыру буенча инициатива күрсәтү турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Урта Курса авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Җирле референдум уздыруны түбәндәге сорау буенча тәкъдим итәргә:

«2018 елда Урта Курса авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 800 сум күләмендә (түләү күләме 400 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш,) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

| | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең аталышы | Планлаштырылган чаралар |
|---|---|---|
| 1 | Җирлекнең җирле әһәмияттәге юлларына карата юл эшчәнлеге | Авыл җирлеге торак пунктларының юл-урам челтәрендә вак таш сатып алу, юл өслеген төзекләндерү буенча хезмәтләр күрсәтү<br>- Югары Курса авылы<br>Яр буе ур., 1дән 5кә йортка кадәр<br>- Урта Курса авылы<br>Яшьләр урамы 1 дән 10 йортка кадәр<br>Яшьләр урамы 1 дән 21 йортка кадәр |
| 2 | Җирлек территориясен төзекләндерү | Урта Курса, Югары Курса, Түбән Курса, Алан, Корайван, Сарай-Чокырча авылларында кече архитектура формалары (балалар мәйданчыклары) сатып алу |

| | | |
|---|---|---|
| | | Югары Курса авылында агачларны санитар кисү |
| | | Урта Курса авылы,<br>Югары Курса авылы, Түбән Курса авылы,<br>Алан, Корайван, Сарай-Чокырча авылы урамнарнын яктырту челтәрләрен ремонтлау |
| 3 | Авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү | Түбән Курса, Алан, Корайван, Сарай-Чокырча авылларында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру |
| 4 | Күмү урыннарын карап тоту | Зират коймаларын ремонтлау өчен материаллар сатып алу<br>Урта Курса авылы, Корайван авылы |

Әйе Юк

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда түбәндәге адреслар буенча мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Урта Курса авылы, Яшьләр ур., 13, Урта Курса авылы, Тукай ур., 21.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ СРЕДНЕКОРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН 1609003070